
# ЦЕНЗУРАГА БИРЕШМӘГӘН ҖИҺАНОВ





Любовь АГЕЕВА
тексты

**ГЫЙНВАР УРТАСЫНДА КАЗАНДА БӨЕК КОМПОЗИТОР ҺӘМ ПЕДАГОГ, КАЗАН КОНСЕРВАТОРИЯСЕНЕҢ «АТАСЫ» НӘҖИП ҖИҺАНОВНЫҢ ТУУЫНА 100 ЕЛ ТУЛУНЫ ТАНТАНАЛЫ ШАРТЛАРДА БИЛГЕЛӘП ҮТТЕЛӘР. СҮЗ УҢАЕННАН, 16 ГЫЙНВАРДА КОНСЕРВАТОРИЯДӘ «ДӨНЬЯ ЯКТЫ БУЛСЫН ӨЧЕН ҖЫРЛЫЙМ МИН...» ӘДӘБИ-МУЗЫКАЛЬ МОНОСПЕКТАКЛЕ КУЕЛДЫ.** СПЕКТАКЛЬНЕҢ НИГЕЗЕНӘ МАЭСТРОНЫҢ ХАТЛАРЫ САЛЫНГАН, Ә УЛ ЭПИСТОЛЯР ЖАНРНЫ, ӘЙТИК, ОПЕРАДАН КИМ ЯРАТМАГАН. НӘҖИП ГАЯЗ УЛЫ ҺӘР УҢАЙДАН ХАТ ЯЗАРГА ЯРАТКАН, КАЙВАКЫТ АЛАРНЫ ТОЗЛЫ-БОРЫЧЛЫ ИТӘРГӘ, ТӨСЛӘРЕН КУЕРТЫП ҖИБӘРЕРГӘ ДӘ КЫЕНСЫНЫП ТОРМАГАН. МУЗЫКАНТНЫҢ БАШКА ЗАМАНДАШЛАРЫНА ДА ХАС БУЛГАН ӘЛЕГЕ ГАДӘТЕ АРКАСЫНДА, БҮГЕНГЕ КӨНДӘ БЕЗНЕҢ КОМПОЗИТОРГА, АНЫҢ АРАЛАШУ ДАИРӘСЕНӘ ҺӘМ ШУЛ ЧОРГА, АНЫҢ ЦЕНЗУРАДАН ДА КУРКЫП ТОРМАГАН СҮЗЛӘРЕ АША КҮЗ САЛЫРГА МӨМКИНЛЕГЕБЕЗ БАР.



**Җ**иһанов хатларын, эше буенча еш булырга туры килгән Мәскәүдән, җитди чире аркасында айлар буена дәваланып ятарга мәҗбүр булган шифаханәләрдән язган. Хатыннарына, балаларына, оныгына, дусларына... Нәҗип Гаяз улының оныгы Алексей Егоров, берүк шәһәрдә яшәсәләр, бер консерваториядә эшләсәләр дә, бабасының кызы Светланага (Алексейның әнисенә) һәрдаим хатлар юллап торуы хакында сөйләде. Алексей бабасының аның үзенә (әле ул чакта яшүсмергә) аталганнарын да кадерләп саклый...

## ■«КҮСЕЛӘР ЧИНАШКАН ТАВЫШЛАР АСТЫНДА ЯЗАМ»

Хат язышу шулчаклы зур күләмле һәм кызыклы булган ки, композиторның төрле никахтан туган балалары — Светлана һәм Иван Җиһановлар, әтиләренең беренче хатыны Серафима Алексеевнага язган хатларын туплап, 2001 елда китап бастырып чыгарганнар. Беренче хатка 1938 елның 24 декабре датасы куелган. Нәҗип Җиһанов, яңа гына Мәскәү консерваториясен тәмамлап, Казанга кайткан. Берничә ел дәвамында монда үзе генә яшәгән, хатлар язышу аны ялгызлыктан коткарган.

1939 елның 2 мартында: «Соң инде. Хатымны бүлем тактасы эчендә сәяхәт итүче күселәр чинашкан тавышлар астында язам. Күргәнеңчә, ялгыз яшәмим, күршеләрем байтак», — дип яза ул.

«Иртән клубка «Качкын»ның оркестр һәм солистлар белән башкарылган II актын тыңларга бардым, сәгать 2 дә Асафьевның «Алтынчәч» операсына тыңлаулар уздырылды. Казан җәмәгатьчелеге чакырулы иде. Миңа беренче булып чыгыш ясарга туры килде. Опера белән алдан ук таныш булганга, әзерлекле идем, билгеле. Чыгышым кискен булды. Хәер, барысы да нигезләнгән иде. Минем чыгыштан соң, башкаларның да телләре чишелде, ә кайберәүләрне чыгыш ясарга, операга карата үз мөнәсәбәтләренең чын дөресен белдерергә мәҗбүр иттеләр, аерып әйткәндә, Стефановичны.

**«Соң инде. Хатымны бүлем тактасы эчендә сәяхәт итүче күселәр чинашкан тавышлар астында язам. Гомумән алганда, күргәнеңчә, ялгыз яшәмим, күршеләрем байтак».**

Операдан баш тарттылар. Теманы, ягъни либреттоны яңа композиторга тәкъдим итәргә тиешләр, мөгаен татаргадыр инде.

Бүген Яруллинның «Шүрәле» балеты тыңлауга куелды. Казан җәмәгатьчелеге бу юлы да чакырулы иде. Шулай ук чыгыш ясадым. Теләктәшлек күрсәттем. Тыңлаучыларда балет яхшы тәэсир калдырды», — дип яза ул 1939 елның 5 маенда.

«Менә инде бер ел буе [Җ. Фәйзи] һаман да операның ничек язылуы серләрен эзли. Язасы бик килә, [ә] шайтаным да белеме юк. Опера үзеннән-үзе язылмый, аның өчен язып бирергә беркем дә ризалашмый, ә бу Җиһанов дигән дуамал бәндә, бер-ике атнадан икенче операсын язып бетерәчәк, мөгаен, өченчесе турында да уйлый башлаячак әле ул, эттән туган нәрсә. Ә нәрсә эшләргә соң? Эш шуңа таба бара: «либретто һич кенә дә йөрәгемә ятмый!» дигәнрәк сылтау табып, опера язудан баш тартыр әле [ул]». (1939 елның 8 маенда язылган хаттан.)

Иван Җиһанов әлеге китапка кереш сүзендә: «Әти олыгайган көнендә дә тойгыларының әчкерсезлеген саклап кала алды, — дип яза, — совет футбол җыелма командасы өчен шатлануы («Блохин!»), КамАЗ эшчеләре үзенә бүләк иткән үзбушаткыч моделенә карата самимилеге («Безнең батыр!»), өстәгеләргә төчеләнеп, Казанның 800 еллыгын бәйрәм итүне булдырмый калуга балаларча ихлас борчылуы («Үпкәләрлек... Мөгез чыгаралар!») — болар барысы да,

**Үзгәртеп кору елларында Җиһановны да тарих тегермәне аямый. Совет елларында казанган абруйлар, мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре инкарь ителә һәм алар, мактаулы билгедән бигрәк, иске режим кешесе икәнлегеңне раслаучы дәлилгә әверелә.**



һичшиксез, аңарга һәрвакытта тормыш сорылыгына, рухи торгынлыкка, милли чикләнгәнлеккә каршы торырга ярдәм итте...

Ул һәрвакыт үз эшенә башы белән чумып, үз-үзен аямыйча хезмәт итте, еш кына — сәламәтлегенә зыян китерү бәрабәренә.

Берүк вакытта аның, беркайчан да якыннары турында онытмыйча, барысын да «алып ташлап», игътибарын бүтән нәрсәгә юнәлтә, тормышның теләсә нинди уңайсызлыкларына җайлаша алу сәләте бар иде — бусы инде аның гомере буена кызыл җеп булып сызылып килгән Ходай бүләге».

## ТАРИХНЫҢ ТЕГЕРМӘН ТАШЛАРЫ

Җиһановка бик күп нәрсә энтузиазмга бәйле булган чорда туу бәхете насыйп булган. Хәтта аерым бер кешенең энтузиазмы турында сөйләсәк тә. Казанда консерватория ачарга теләгең бар икән — ачтың, симфоник оркестр оештырырга уйладыңмы — оештырдың... Артык гадиләштерү бу, билгеле. Аның белән иңгә-иң торып, башкалар да эшләгән бит, барыннан да бигрәк республика җитәкчелеге. Әмма Нәҗип Гаяз улы булмаса, Татарстанның һәм татар халкының музыкаль тарихы үсеше бөтенләй башка юлдан китәр иде. П.И.Чайковский исемендәге Мәскәү дәүләт консерваториясе профессоры, чирек гасыр дәвамында Казан консерваториясендә эшләп киткән Альберт Леман, СССР Зур театрының атаклы режиссеры, «Җәлил» операсын Казанда да, Мәскәүдә дә сәхнәгә куйган Борис Покровский, СССР Композиторлар берлеге идарәсе җитәкчесе Тихон Хренников әнә шундый фикердә булганнар.

Үзгәртеп кору елларында Җиһановны да тарих тегермәне аямый. Совет елларында казанган абруйлар, мактаулы исемнәр, дәүләт бүләкләре инкарь ителә һәм алар, мактаулы билгедән бигрәк, иске режим кешесе икәнлегеңне раслаучы дәлилгә әверелә. Татар музыкасында өстенлекле юнәлешләр Көнчыгыштан Көнбатыш ягына үзгәрә. Шул вакытта җәмгатьчелек арасында: «татар өчен кем әһәмиятлерәк: Җиһановмы әллә Сәйдәшевме» дигән буш бәхәс китереп чыгаручылар да табыла. Соңрак Нәҗип Җиһановның Фәрит Яруллин белән «араларын бозарга» маташып карыйлар (Диас Вәлиев бу хакта «Хәтта үлгәннәрне дә үтерәләр» дигән документаль повесть яза). Җиһановны, коллегасын фронтка җибәреп, асылда, аны һәлак итүдә гаеплиләр. Диас Вәлиев, фактлар китереп, әлеге гаеп тагуларны җентекләп аерып, тар-мар итә итүен. Аерып әйткәндә, Фәрит Яруллинның хатынының Җиһановка юлланган хатларыннан күренгәнчә, композитор һәлак булган дустының гаиләсенә дистә еллар дәвамында сүз белән дә, эш белән дә ярдәм итеп килә. Һәм ул берүзе генә булыша. Композиторның кызы Наилә Яруллинаның 1965 елның 2 сентябрендә Нәҗип Җиһановка язган хатыннан:

«Минем якты хыялым тормышка ашканга — туган җиремә барып кайтуыма өч ай тулды. Хәзер минем алдымда фотографияләр ята һәм мин Казанда уздырган искиткеч көннәремне кабат-кабат искә төшереп, әниемә һәм әбиемә сөйләп, хатирәләремне яңартам. Бабам һәм әтием туып-үскән, белем алган, эшләгән шәһәр миңа бик ошады.

Нәҗип Гаязович, Композиторлар берлегендә оештырган очрашуыгыз өчен мин Сезгә аеруча рәхмәтлемен. Анда мине шулчаклы ихлас җылы каршыладылар ки, беркайчан да ул көндәгечә дулкынланганым юк иде. Гомеремдә беренче мәртәбә сүзсез басып тордым, миңа күрсәткән игътибарлары өчен, бөтен кешегә дә рәхмәтемне белдерү түгел, хәтта бер адым да атларлык хәлдә түгел идем».

Диас Вәлиев, дустының «Шүрәле» балетына авторлык хокукларын торгызу өчен, Нәҗип Гаязовичның берничә ел дәвамында ничек итеп көрәшүе хакында сөйләгән иде, чөнки балетны Мәскәүдә һәм Ленинградта куяр өчен, партитурасына үзгәрешләр керткән булалар, шунлыктан Мәскәүнең ике композиторы әлеге әсәргә авторлык хокукларын дәгъвалый. Бүгенге көндә әлеге фактлар турында Казанда бик азлар гына белә торгандыр.

**Татар музыкасында өстенлекле юнәлешләр Көнчыгыштан Көнбатыш ягына үзгәрә. Шул вакытта җәмәгатьчелек арасында: «татар өчен кем әһәмиятлерәк: Җиһановмы әллә Сәйдәшевме» дигән буш бәхәс китереп чыгаручылар да табыла.**

## ОРКЕСТР «ЧОКЫРЫ»

Исеме дөньяга танылган дирижер

»
«Симфоник оркестрны, әйтергә кирәк, аяктан ектылар... Бөтенесенең башында бер генә уй: акча да акча. Ә эшлиселәре килми. Оркестрның музыка сәнгатен яңа югарылыкка күтәрердәй мөмкинлек тудыра алуын аңламыйлар. Аларны бүгенге дә тулысынча канәгатьләндерә. Мондый торгынлык белән бер генә кешенең көрәшүе аз. Моңа минем гомерем генә җитмәстер, курәсең».





Натан Рахлинның Киевтан Казанга күченеп килүендә, республикабыз әлеге атаклы шәхеснең Җиһанов белән танышлыгына бурычлы икәнлеген кем генә хәтерли икән? Нәҗип Гаяз улы Рахлинны Украина башкаласын ТАССРныкына алыштырырга күндереп кенә калмаган, республика җитәкчелеге ярдәмендә ТР Дәүләт симфоник оркестрының беренче художество җитәкчесенең һәм баш дирижерының бик күп көнкүреш проблемаларын да хәл иткән.

Ничә елдан бирле кайберәүләр тарафыннан Җиһанов исеме аңлы рәвештә әлеге оркестр тарихыннан агулап-сөрелеп чыгарыла. Әмма менә алар — документаль шаһитлар, алар белән бәхәсләшүе авыр.

1964 елның 30 августында Нина Җиһановага Мисхордан җибәргән хатыннан:

«Симфоник оркестрны, әйтергә кирәк, аяктан ектылар... Бөтенесенең башында бер генә уй: акча да акча. Филармония күпмедер дәрәҗәдә үз-үзен аклый әле, дотацияләр сорамый. Ә оркестр турында кайгыртырга, эшләргә кирәк. Ә эшлиселәре килми. Оркестрның музыка сәнгатен яңа югарылыкка күтәрердәй мөмкинлек тудыра алуын аңламыйлар. Аларны бүгенге дә тулысынча канәгатьләндерә. Мондый торгынлык белән бер генә кешенең көрәшүе аз. Моңа минем гомерем генә җитмәстер, күрәсең. Менә тагын Альберт (Леман, Казан консерваториясенең ул чактагы профессоры. — Авт.) көрәшә, калганнар, язасы, җәмәгатьчелек фикерен тудырасы урынга, нидер көтәләр!

Хәтта бер эшлекле бәндә оркестр композиторларга гына хаҗәт ул (?!), дип тә ычкындырды. Барып җиттек бугай...»

1966 елның 3 октябрендә Нина Җиһановага Железноводскидан җибәргән хатыннан:

«Рахлин белән икәүләп Вәлиевкә (КПСС Өлкә комитетының ул чактагы идеология мәсьәләләре буенча секретаре. — Авт.) керәчәкбез; мин көткәнчә булып чыкты: Рахлинның күчеп килгән төшенә аның үзенә дә, оркестрантларына да фатирлар юк... Репетицияләр уздыру өчен урын арендалауга килешү дә төзелмәгән. Гомумән алганда — бардак.

Барысы да миңа шалтырата. Ә мин нишли алам соң? Һаман да йөрим, көрәшәм. Ә мәгънәсе кайда?.. Үз төзелешем дә туктап калды. Менә ике атнадан артык инде анда бер генә эшченең дә күренгәне юк! (Сүз консерваториянең актлар залы төзелеше хакында бара. — Авт.) Яхшы һәм күңелле яшибез...»

Натан Рахлин да үзенең хатында оркестрның нигездә Нәҗип Җиһановның кайгыртуы аркасында оешуын билгеләп үтә.

## СОВЕТ МУЗЫКАСЫНЫҢ НАМУСЫ

Балалар йортында үскәннәргә хас булганча, Нәҗип Гаяз улы искиткеч көчле һәм гаярь кеше була, хәтта гомере азагына якынлашып килгән мәлдә, «Советская культура» газетасында аны нигездә нахакка гаепләгән мәкалә басылып чыккач та, язмыш сынавын, һәрвакыттагыча, сабырлык белән үткәреп җибәрергә тырыша.

Җиһановның эпистоляр мирасына күз салсак, 1965 елның 26 феврале датасы куелган бер хатында гына ул үзенең көчсезлеге хакында Нина Ильиничнага нибары берничә юл яза. Мәскәүдән юллый ул хатны:

«Гомумән, консерватория минем иң яхшы елларымны тартып алды. Бу тынгысыз-борчулы дөньяны ташлап киткәч, исемемне җылы сүз белән искә төшерүчеләр булырмы икән, белмим...»

«Гомумән, консерватория минем иң яхшы елларымны тартып алды. Бу тынгысыз-борчулы дөньяны ташлап киткәч, исемемне җылы сүз белән искә төшерүчеләр булырмы икән, белмим...»

1971 елның 14 гыйнварында Җиһановка Тихон Хренников: «Кадерле дустым, Нәҗип! Син безнең композиторлар корпорациясенең совет музыкасының намусы дип атарлык иҗади шәхесләре рәтенә керәсең...», — дип яза.

Шунысы күңелне юата: Нәҗип Гаяз улы әлеге юлларны үзе исән чакта укып өлгергән. Кызганычка, кешеләр арасында адәми затларның казанышлары турындагы чынбарлыкны алар үлгәч кенә зурлап сөйләү кабул ителгән. Ярый әле мондый очрак өчен йөз еллык юбилейлар булгалап куя.

P.S. «Казанские истории» Интернет-газетасының баш мөхәррире Любовь Агеева материалының тулы версиясен www.history-kazan.ru. сайтыннан укып була.

**Чыганак:** *Татарстан.- 2011.- № 2.- Б.56-59.*